**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«21» 09 2023 ел Яр Чаллы № 110

Әҗмәкәй авыл җирлегендә урнашкан 16:39:021201:1639 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, Тукай муниципаль районы Уставы, район Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (район Советының 2022 елның 9 декабрендәге 27/8 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), Тукай муниципаль районының җирдән файдалану һәм авыл җирлекләре төзелешен алып бару кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча ведомствоара комиссиясенең 2023 елның 15 сентябрендәге карары нигезендә

## КАРАР БИРӘМ

1. Әҗмәкәй авыл җирлегендә урнашкан 16:39:021201:1639 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «Шәхси торак йортлар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлеге» төп төрдән «Кибетләр» шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2.1. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга.

2.2. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты Юл» («Светлый Путь») газетасында бастырып чыгарырга.

3. Билгеләргә:

3.1. үткәрү вакытын: 2023 елның 11 октябрендә 16:00 сәгатьтә, үткәрү урынын: Новый поселогы, Үзәк ур., 1, авыл мәдәният йорты;

3.2. проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү өчен адрес: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46, 203 каб.;

3.3. тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2023 елның 27 сентябреннән 2023 елның 11 октябренә кадәр кабул ителә.

4. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше секторы мөдире О.А. Никитинаны билгеләргә.

5. Фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2023 елның 21.09 110 номерлы карарына кушымта

Фикер алышуда гражданнарының катнашу тәртибе

Әлеге тәртип җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм гражданнарының фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына Тукай муниципаль районы халкы тарафыннан язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр **2023 елның 27 сентябреннән 2023 елның 11 октябренә кадәр** түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил пр., 46, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 каб.

3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

4. Халык тыңлаулары секретаре фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

5. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.

6. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

7. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.

8. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә: халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме; халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны; халык тыңлауларында катнашкан гражданнарының саны; халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

9. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм мәҗбүри рәвештә «Якты Юл» («Светлый Путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.